**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 июлендәге 2783 номерлы карары**

**Декабристлар урамындагы территорияне**
**планлаштыру проектын раслау турында**

Территорияләрне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46, 66 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы карары нигезендә, 2023 елга «Казан шәһәрен үстерү институты» МБУ муниципаль йөкләмәсен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Декабристлар урамындагы территорияне планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кызыл линияләрне, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләрен күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымына кушымта) (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) тыш, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
1 июлендәге 2783 номерлы
карары белән расланган

**Декабристлар урамындагы территорияне планлаштыру проекты**

Декабристлар урамындагы территорияне планлаштыру проектының төп өлеше түбәндәгеләрдән тора:

I. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләрен күрсәтелгән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге беркетелгән территорияне планлаштыру проекты сызымы.

II. Территорияне план буенча үстерүнең характеристикалары турындагы нигезләмәләр.

III. Территорияне план буенча үстерүнең чираты турында нигезләмә.

IV. Тартып алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге.

Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге (кызыл линияләрне, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләрен күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымына кушымта) хезмәт урынында файдалану өчен материал булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) белән Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

I. Чертеж планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ:

граница проекта планировки территории

красные линии устанавливаемые

зона благоустройства территории общего пользования

зона улично-дорожной сети

14 ● номера характерных точек красных линий

## II. Территорияне план буенча үстерүнең характеристикалары турында нигезләмә

### 1. Планлаштыру проектының чикләре

Декабристлар урамы территориясен планлаштыру проекты чикләре:

- төньяктан – Шамил Усманов урамы – район әһәмиятендәге магистраль урам;
- көнчыгыштан – Декабристлар урамы – гомумшәһәр әһәмиятендәге хәрәкәт итү көйләүле булган магистраль урам;
- көнбатыштан – Энергетиклар урамы – җирле әһәмияткә ия урам.

Планлаштыру проекты чикләрендәге территориянең мәйданы 0,95 га тәшкил итә.

### 2. Карала торган территориянең характеристикалары

Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы (алга таба – Казан шәһәренең Генераль планы) нигезендә карала торган территориягә территориаль зона – иҗтимагый функцияләр өлеше югары булган күп фатирлы торак төзелешен урнаштыру зонасы (зона индексы 210) билгеләнгән. Казан шәһәренең Генераль планының табигый-рекреацион каркасы картасы нигезендә территориядә 1234 кв. м мәйданлы мини-сквер урнашкан.

Планлаштыру проекты чикләрендәге территория гомуми мәйданы 0,7582 га булган торак булмаган төзелеш территориясе комплекслы үстерелергә тиеш.

Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә территория территориаль иҗтимагый-торак зонада – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасында урнашкан. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең ярдәмче зоналары картасы нигезендә территория өлешчә территорияләрдән файдалануның югары интенсивлыгы зонасында урнашкан.

Территорияне планлаштыру проекты территориясе район әһәмиятендәге: Шамил Усманов урамы; гомумшәһәр әһәмиятендәге: Декабристлар урамы; җирле әһәмияттәге: Энергетиклар урамы белән чикләнгән.

### 3. Территорияне план буенча үстерү характеристикасы

Планлаштыру проекты нигезендә гомуми мәйданы 9322 кв. м булган территорияне комплекслы төзекләндерү һәм яшелләндерү белән сквер булдыру күздә тотыла.

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә капиталь төзелеш объектларын урнаштыру каралмаган.

## 4. Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикалары

Планлаштыру проекты территориясен шәһәр җәмәгать транспортының төрле төрләре белән тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү планлаштырыла (Шамил Усманов, Декабристлар урамнары буенча троллейбус, автобус линияләре, «Яшьлек» метро станциясе).

Планлаштыру проекты территориясе Шамил Усманов, Декабристлар, Энергетиклар, Тверь, Волгоград урамнары буенча төп җәяүлеләр элемтәләре белән тәэмин ителгән.

Территорияне планлаштыру проектында парковка урыннары каралмаган, җәяүлеләр өчен уңайлы радиуста «Яшьлек» метро станциясе урнашкан.

## 5. Инженер-техник яктан тәэмин итү системасын үстерү характеристикалары

Кече архитектура формаларын инженер-техник тәэмин итү кирәк булганда эксплуатацияләүче оешмалар биргән техник шартлар нигезендә проектланачак.

Эшне проектлау стадиясендә комплекслы үстерү каралган территориядә урнашкан «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенең капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү һәм демонтажлау кирәк булуын истә тотарга кирәк.

Эшне проектлау стадиясендә коррозиядән саклану чараларын алга таба эксплуатацияләү максатларында проект карары белән дренаж кабелен һәм анод контурын төзелеш зонасыннан чыгаруны күздә тотарга кирәк. Техник шартлар алу һәм проект карарларын килештерү өчен «Казаньгоргаз» эксплуатация-җитештерү идарәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Сквер төзегәндә һәм булган биналарны ликвидацияләгәндә, территориядән киләчәктә имин файдалану өчен, эшне проектлаштыру стадиясендә су белән тәэмин итү һәм су үткәрү челтәрләрен демонтажлауны

күз алдында тотарга кирәк. Су белән тәэмин итү һәм су үткәрү челтәрләрен демонтажлауны «Водоканал» МУП белән килештерергә кирәк.

## III. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә

1 нче этап. Төзекләндерү проект документациясен әзерләү (сквер).

2 нче этап. Кече архитектура формаларын урнаштыру белән скверны төзекләндерү.

## IV. Тартып алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

Скверны оештыру максатларында җир кишәрлекләрен тартып алу өчен нигез булып территорияне комплекслы үстерү (ТКҮ) тора.

Җирле әһәмияткә ия объектны – скверны урнаштыру максатларында тартып алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге таблицада күрсәтелгән.

Таблица

| № т/б | Кадастр номеры, тамгаланышы, объектның исәп номеры | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Тартып алу |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:100419:23 | 16.38 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 2 | 16:50:100419:61 | 19 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 3 | 16:50:100419:1160 | 68 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 4 | 16:50:100419:19 | 103 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 5 | 16:50:100419:1159 | 221 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 6 | 16:50:100419:1155 | 58 | Территорияне | Тулысынча |

| № т/б | Кадастр номеры, тамгаланышы, объектның исәп номеры | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Тартып алу |
|---|---|---|---|---|
| | | | төзекләндерү (12.0.2) | |
| 7 | 16:50:100419:1291 | 404 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 8 | 16:50:100419:1255 | 184 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 9 | 16:50:100419:1154 | 206 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 10 | 16:50:100419:1241 | 273 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 11 | 16:50:100419:1162 | 342 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 12 | 16:50:100419:70 | 358 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Резервлау |
| 13 | 16:50:100419:69 | 120 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |
| 14 | 16:50:100419:20 | 740 | Территорияне төзекләндерү (12.0.2) | Тулысынча |